РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» март 2021 ел г. Альметьевск № 307

Гражданнарны наем шартнамәләре
буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар
дип тану максатларында гражданнарның
һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә
әгъзаларының кеременең һәм аларның
салым салынырга тиешле мөлкәтләре
хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен түбәндәге очракларда билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 779 327 сум.;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 264 598 сум.;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 911 626 сум.;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 882 168 сум.;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 852 710 сум.;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5 823 252 сум.;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 793 794 сум.;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 764 336 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме тәшкил итә

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданга – 44 004 сум.;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 28 003 сум.;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 24 002 сум.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ